**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Комыргуҗа авыл җирлеге Советы карары**

**Карар № 107**

Комыргуҗа авылы "20" декабрь 2024 ел

**Комыргуҗа авыл җирлеге Советының 2009 елның 6 августындагы 16 номерлы карары белән расланган "Җирле үзидарә органында муниципаль хезмәткәрнең шәхси белешмәләре белән эшне оештыру һәм аның шәхси эшен алып бару" турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу турында «Федераль закон һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында «Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 08.06.2020 ел №181-ФЗ Федераль закон нигезендә, «Россия Федерациясе дәүләт хезмәте системасы турында» Федераль законның 12 статьясына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 12 декабрендәге 594-ФЗ номерлы Федераль закон белән, прокурорның 2024 елныд 30 сентяберендәге №02-08-02-2024/прдп386-24-20920010 номерлы протесты нигезендә, Әтнә муниципаль районының «Комыргуҗа авыл җирлеге» муниципаль берәмлек Уставына таянып», Әтнә муниципаль районының Комыргуҗа авыл җирлеге Советы **КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Советының 2009 елның 3 июлендәге 16 номерлы карары белән расланган "Җирле үзидарә органында муниципаль хезмәткәрнең шәхси белешмәләре белән эшне оештыру һәм аның шәхси эшен алып бару" турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертергә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча http://pravo.tatarstan.ru һәм Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында http://atnya.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне үз җаваплылыгымда калдырам.

Әтнә муниципаль районы
Комыргуҗа авыл җирлеге башлыгы Гатауллин Ф.Т.

СОВЕТ КОМОРГУЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
КОМЫРГУҖА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
ИНН 1610000733

Комыргужа авыл җирлеге
Советының
2024 елның 20 нче декарендәге
107 номерлы карарына кушымта

**Комыргужа авыл җирлеге Советының 2009 елның 6 августындагы 16 номерлы карары белән расланган “Җирле үзидарә органында муниципаль хезмәткәрнең шәхси белешмәләре белән эшне оештыру һәм аның шәхси эшен алып бару” турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр:**

**1) 2 бүлекнең 2.2 пунктчасында** «алу, саклау, тапшыру һәм башка төрле файдалану» сүзләрен «эшкәртү» сүзенә алмаштырырга.;

**2) 2 бүлекнең 2.5 пунктындагы 2 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:** «муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 15.2 статьясында каралган анкетаны;

**3) 2 бүлекнең 2.5 пунктындагы 4 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:** « законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хезмәт кенәгәсен һәм (яисә) хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләрне, хезмәт шартнамәсе (контракты) беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш»;

**4) 2 бүлекнең 2.5 пунктындагы 6 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:** «хезмәт шартнамәсе (контракты) беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш, индивидуаль (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслый торган документ»;

**5) 2 бүлекнең 2.5 пунктындагы 8 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә**: «хәрби исәпкә алу документлары – запаста булган гражданнар һәм хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле затлар өчен»;

**6) 2 бүлекнең 2.5 пунктындагы 9 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә**: «"гражданның муниципаль хезмәткә керүенә яисә аны узуына комачаулый торган авыру булмавы турында билгеләнгән рәвештәге медицина бәяләмәсе»;

**7) 2 бүлекнең 2.5 пунктына түбәндәге эчтәлекле 10.1 пунктчасы өстәргә**: "10.1) «муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 15.1 статьясында каралган белешмәләрне»;

**8) 2 бүлекнең 2.6 пунктында:** «белешмәләрне» сүзеннән соң «(анкетадагы белешмәләрдән тыш)» сүзләрен өстәргә»;

**9) 7 бүлекнең 7.3 пунктындагы 5 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:** «хезмәт кенәгәсенең күчермәсе һәм (яисә) хезмәт эшчәнлеге турында Федерация законнарында билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән белешмәләр, хәрби яисә башка хезмәт узуын (булган очракта) раслый торган документның күчермәсе»;

**10) 7 бүлекнең 7.3 пунктындагы 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә**: «белем һәм (яисә) квалификация турындагы документларның, гыйльми

дәрәҗә, гыйльми исем бирү турындагы документларның (әгәр андыйлар булса) күчермәләрен»;

**11) 7 бүлекнең 7.3 пунктындагы 14 пунктчасын төшереп калдырырга;**

**12) 7 бүлекнең 7.3 пунктындагы 21 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:** индивидуаль (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслый торган документның күчермәсе»;

**13) 7 бүлекнең 7.6 пунктына түбәндәге пунктча өстәргә: «5)** граждан хезмәткәрләренең гражданлык хезмәтен узу чоры өчен хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр булдыруны һәм күрсәтелгән белешмәләрне Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондының мәгълүмат системаларында саклау өчен мәҗбүри пенсия иминияте һәм мәҗбүри социаль иминият системаларында индивидуаль (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә тапшыруны тәэмин итү (дәүләт серен тәшкил итүче мәгълүматлардән кала).».

Әтнә муниципаль районы
Комыргуҗа авыл җирлеге башлыгы Гатауллин Ф.Т.

СОВЕТ КОМОРГУЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КОМЫРГУҖА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ ИНН 1610000733